**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

---

**2021елның 29 ноябре** **101-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Столбище авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә (җирле үзидарә органнарына)җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыруны тапшыру турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 3 өлешенә, 15 статьясындагы 4 өлешенә,Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.5 статьясына, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ**:**

1. «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенә (җирле үзидарә органнарына) «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 20 пунктында каралган вәкаләтләрнең бер өлешен бирергә, тәгәлрәге, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге генераль планын һәм җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен килешү төзү юлы белән раслау.
2. Әлеге карарны карау өчен Лаеш муниципаль районының Столбище авыл җирлеге советына җибәрергә.
3. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
4. Әлеге карар басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә).
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**